| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

# Татарстан Республикасы Тукай районының Бордыбаш авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Тукай районының Бордыбаш авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Тукай районының Бордыбаш авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2016 елның 30 апрелендәге ПУ-391 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 06 июль
№ ПУ-581